КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 14 ноябрь г.Казань № 1004

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карары белән расланган Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бөртекле культуралар җитештерүчеләргә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 7 сентябрь, 836 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 27 июнь, 608 нче; 2022 ел, 21 октябрь, 1130 нчы; 2022 ел, 11 ноябрь, 1204 нче; 2023 ел, 20 март, 279 нчы; 2023 ел, 29 май, 649 нчы, 2023 ел, 5 декабрь, 1561 нче, 2024 ел, 5 апрель, 232 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Бөртекле культуралар җитештерүгә һәм реализацияләүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен бөртекле культуралар җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның икенче абзацында «сатылган бөртекле культуралар» сүзләрен «сатылган ашлык» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«ашлык - бөртекле культураларның җимешләре.»;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен субсидиядән файдалану нәтиҗәсенең түбәндәге мәгънәсе кулланыла: сайлап алуны үткәрү турында игълан итүдә күрсәтелгән чорларда үзләре җитештергән бөртекле культураларның күләмнәренә ирешелгән (мең тонна).»;

52 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин